КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 5 июль г.Казань № 544

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 9 июнь, 438 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 9 июнь, 438 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 29 сентябрь, 875 нче; 2019 ел, 15 май, 397 нче; 2021 ел, 19 апрель, 256 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Татарстан Республикасы Гарантия фонды» коммерциягә карамаган оешмасы чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү (каплау) өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче

карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының (алга таба – дәүләт программасы) «2018 – 2024 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасында (алга таба – ярдәмче программа) каралган түбәндәге чараларны гамәлгә ашыру максатларында тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында каралган бюджет ассигнованиеләре, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба – Министрлык) тиешле финанс елына субсидия бирүгә бюджет акчасын алучы буларак җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә:

а) чараны гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү максатларында – төбәк гарантия оешмалары тарафыннан кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына җаваплылыкны үз өстенә алудан файдалану мөмкинлеге (гарантияләр) бирү;

б) чараны гамәлгә ашыруга чыгымнарны финанслар белән тәэмин итү (каплау) максатларында – Татарстан Республикасында хакимият белән бизнесның үзара хезмәттәшлеге системасын оештыру.

Әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Татарстан Республикасы бюджеты акчасы тора.»;

10 пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

11 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Субсидия бирү Министрлык һәм Фонд арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә төзелә.»;

икенче һәм өченче абзацларны төшереп калдырырга;

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Министрлык һәм Фонд, кирәк булуга карап, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган, килешүнең бертип формасына теркәлә торган форма буенча килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.»;

унсигезенче һәм унтугызынчы абзацларны төшереп калдырырга;

13 пунктта:

«а» пунктчасының икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«килешүнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формасына теркәлә торган форма буенча финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны башкару турында хисап. Әлеге хисап – хисап кварталыннан соң килә торган бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, IV квартал өчен хисап субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр тапшырыла;

килешүнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формасына теркәлә торган форма буенча субсидия бирү

нәтиҗәләренә ирешү турында хисап. Әлеге хисап – хисап кварталыннан соң килә торган бишенче эш көненнән дә соңга калмыйча, IV квартал өчен хисап субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 15 гыйнварына кадәр тапшырыла;»;

«б» пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«килешүнең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип формасына теркәлә торган форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап. Әлеге хисап Килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә тапшырыла;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин